КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 12 февраль г.Казань № 77

Татарстан Республикасының Патриотик тәрбия буенча координация советын төзү турында

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары һәм иҗтимагый оешмаларның Татарстан Республикасында яшьләрне патриотик тәрбияләү буенча багланышларын камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының Татарстан Республикасының Патриотик тәрбия буенча координация советын төзү турында тәкъдимен кабул итәргә.
2. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасының Патриотик тәрбия буенча координация советы турында нигезләмәне һәм аның составын расларга.
3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин